ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар жыены нәтиҗәләре турында

**от 24.10.2025** **№ 1**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2025 елның 24 октяберендә 12 сәгать 00 минутта, 2025 елның 24 октяберендә 12 сәгать 30 минутта этаплап уздырылган гражданнар жыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

«2026 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле киткәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, хатыннары, балигъ булмаган балаларыннан) тыш,яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым акчалары жыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; халыкка су бирү (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирән насосларны сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау, су колонкаларын ремонтлау) һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар.

3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу һәм янгын сүндерү

автомобилен карап тоту) янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү һәм башка чыгымнар;

4. Кадыбаш авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту чокырларга ремонт (Тау асты, Яшьләр, Гали урамы юлларына вак таш, ком сатып алу һәм салу, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

5. Торак пункт территориясен ( үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү: Кадыбаш авылында дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу; тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар).».

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 236 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 145 кеше, бу 61,44 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 145 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «2026 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле киткәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, хатыннары, балигъ булмаган балаларыннан) тыш,яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

3.1 Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен

материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

3.2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; халыкка су бирү (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу; җирлекне су белән тәэмин итү (тирән насосларны сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау, су колонкаларын ремонтлау) һәм су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар.

3.3 Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу һәм янгын сүндерү автомобилен карап тоту) янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү һәм башка чыгымнар;

3.4 Кадыбаш авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту чокырларга ремонт (Тау асты, Яшьләр, Гали урамы юлларына вак таш, ком сатып алу һәм салу, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

3.5. Торак пункт территориясен (Балаларның уен мәйданчыгы өчен җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү: Кадыбаш авылында дизель ягулыгы, дизель мае, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу; тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар)».

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы — Х.Л.ЗАКИРОВ

Совет Кадыбашского сельского поселения
Кадыбаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601003572